**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**«16» октябрь, 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә җыюны кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-җәяүлеләр өчен күперләр ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-кое,чишмәләр ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

-сүүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

-юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г)ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

-зиратларның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау, моның өчен материаллар һәм җиһазлар сатып алу ;

- зират коймасын тотып алу, моның өчен материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан

Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина